**«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Кариле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**“04” сентябрь 2023 ел** **№ 91**

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Кариле авыл җирлегенең«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Кариле авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр, шулай ук Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Кариле авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакында» 2016 елның 21 апрелендәге 23 номерлы карарына үзгәрешләр кертү

«Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Кариле җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1.Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Кариле авыл җирлегенең «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Кариле авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр, шулай ук Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Кариле авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакында» 2016 елның 21 апрелендәге 23 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. түбәндәге эчтәлекле 3.1 өлеш өстәргә:

«3.1. Әгәр федераль законда башкасы билгеләнмәгән булса, муниципаль вазыйфаны биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы

йөкләмәләре турында Россия Федерациясе субъекты законы белән билгеләнгән тәртиптә Россия Федерациясе субъектының югары вазыйфаи затына үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыра».

1.2. 8 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутатының муниципаль вазыйфасын биләүче һәм даими булмаган нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы зат депутат булып сайланган көннән алып дүрт ай эчендә керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында күрсәтелгән белешмәләрне тапшыра, аңа вакантлы депутат мандатын тапшыра. Муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутатының муниципаль вазыйфасын биләүче һәм үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы зат «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар һәм аларның керемнәре чыгымнарының туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 1 өлешендә каралган очракларда керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында Россия Федерациясе законнары нигезендә белешмәләр тапшыра.Хисап чоры дәвамында «Дәүләт Вазыйфаларын биләүче затлар һәм аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 1 өлешендә каралган алыш-биреш башкарылмаган, гомуми суммасы әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) хисап чорына кадәрге соңгы өч елдагы гомуми кеременнән артып киткән очракта, муниципаль берәмлек вәкиллекле органы депутатының муниципаль вазыйфасын биләүче һәм үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы зат бу хакта Россия Федерациясе субъекты законында билгеләнгән тәртиптә Россия Федерациясе субъектының иң югары вазыйфаи затына хәбәр итә. Муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутатының муниципаль Вазыйфаларын биләүче затлар турында мәгълүматтан, керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләрдән, мондый затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белә торып дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр бирү турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү федераль законнар, Россия Федерациясе Президенты указлары нигезендә гамәлгә ашырыла. Муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутатының муниципаль вазыйфаларын биләүче затларның муниципаль вазыйфалары турында гомумиләштерелгән мәгълүмат, керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләрне Россия Федерациясе субъекты законы белән билгеләнгән тәртиптә җирле үзидарә органнарының рәсми сайтларында (мондый мәгълүматта тиешле затны идентификацияләү мөмкинлеген бирә торган шәхси мәгълүматлар булмаган очракта һәм тиешле затка караган мөлкәтне индивидуаль реализацияләргә мөмкинлек бирә торган мәгълүматлар) урнаштырыла. Муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутатының муниципаль вазыйфаларын биләүче затларга әлеге Нигезләмәнең 13 пункты кагыйдәләре кулланылмый.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация

челтәрендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районы Олы Кариле
авыл җирлеге башлыгы,
Татарстан Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районы Олы Кариле
авыл җирлеге Советы рәисе Ф.Г.Гарифуллин